ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

пр. Строителей, д.12, г. Нижнекамск, 423570

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

11 02 2022 г. № 77

Түбән Кама муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында гражданнарның аерым категорияләре өчен түләүсез туклану белән тәэмин итү хокукын озайту турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясы нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Түбән Кама муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында, Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумы күләменә бәйсез рәвештә, 18 яшькә кадәр 4 һәм аннан күбрәк балалары булган күпбалалы гаиләләрдәге укучы балалар категориясе өчен түләүсез туклану белән тәэмин итү хокукын 2022 елның 1 апреленә кадәр озайтырга.

2. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсенә (Гарифуллин А.Х.) Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 25 июлендәге 476 номерлы «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары укучыларын 2017 елның 1 сентябреннән тукландыруны оештыру турында» карары белән билгеләнгән ташламалар бирү өчен нигез булып торган документларны гомуми белем бирү оешмаларына вакытында тапшыру кирәклеге турында әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән укучыларның ата-аналарына мәгълүмат бирүне тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (Мәхмүтов А.Г.), Татарстан Республикасы Социаль яклау министрлыгының Түбән Кама муниципаль районындагы Социаль яклау идарәсе (Романова С.А.) белән берлектә, әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән мөрәҗәгать иткән укучыларның ата-аналары тарафыннан Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумыннан түбәнрәк җан башына уртача керем булуын раслаучы документларны үз вакытында алу эшен оештырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә һәм 2022 елның 11 февраленнән барлыкка килгән мөнәсәбәтләргә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.Г. Мәхмүтовка йөкләргә.

Җитәкче Р.Х. Муллин

ДЛЯ ДОКУМЕНТОВ
ДОКУМЕНТЛАР ӨЧЕН
ИНН 1651044874